КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 октябрь г.Казань № 1335

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 октябрь, 731 нче, 2014 ел, 29 ноябрь, 930 нчы, 2014 ел, 12 декабрь, 982 нче, 2015 ел, 4 август, 566 нчы, 2015 ел, 5 сентябрь, 640 нчы, 2016 ел, 27 сентябрь, 689 нчы, 2017 ел, 24 апрель, 241 нче, 2017 ел, 28 июнь, 450 нче, 2018 ел, 26 июнь, 520 нче, 2018 ел, 19 декабрь, 1173 нче, 2019 ел, 2 сентябрь, 754 нче, 2020 ел, 28 гыйнвар, 47 нче, 2020 ел, 16 июль, 601 нче, 2021 ел, 29 апрель, 297 нче, 2021 ел, 13 сентябрь, 863 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1327 нче, 2022 ел, 29 август, 925 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1454 нче; 2023 ел, 18 апрель, 484 нче; 2023 ел, 2 июнь, 675 нче; 2023 ел, 14 июль, 836 нчы; 2023 ел, 29 сентябрь, 1199 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның I бүлегендәге егерме алтынчы абзацында «Халык иҗатына ярдәм күрсәтү. 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы төп халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында мәдәни идентификация һәм этномәдәни үсеш факторы буларак Татарстан Республикасы җирле халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру өчен оптималь шартлар тудыру каралды» сүзләрен «Халык иҗатына ярдәм күрсәтү. 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы төп халыкларының матди булмаган этномәдәни байлыгын саклап калу,

торгызу һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында мәдәни идентификация һәм этномәдәни үсеш факторы буларак Татарстан Республикасы җирле халыкларының матди булмаган этномәдәни байлыгын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру өчен оптималь шартлар тудыру каралды» сүзләренә алмаштырырга;

Программага 4 нче кушымтада:

«Мигрантларны социаль һәм мәдәни адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү» юлының 2 графасында «ТР ХХЭбТИhСЯ» сүзләрен «ТР ИМ, ТР ХХЭбТИhСЯ, СЮККО ярдәм күрсәтү буенча ресурс үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.8. Беларусь һәм Россия халыклары берләшү көненә багышланган чаралар үткәрү | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ, ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2014 – 2019 еллар, 2021 – 2025 еллар | Беларусь һәм Россия халыклары берләшү көненә багышланган чараларда катнашучылар саны, шул исәптән онлайн, кеше | 1 500 | 1 550 | 1 600 | 1 650 | 1 700 | 1 750 | 1 800 | - | 1 900 | 2 050 | 2 050 | 2 050 | 2 100 | 0,2 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,2 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,2 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,21 (Татарстан Республикасы бюджеты), 0,1233 (федераль бюджет) | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,23 (Татарстан Республикасы бюджеты) | - | 0,1045 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,24 (Татарстан Республикасы бюджеты), 0,36 (федераль бюджет) | 0,6 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,24 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,24 (Татарстан Республикасы бюджеты)»; |

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.4. Татарстан Республикасында хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә комплекслы якын килүне тәэмин итү проектын гамәлгә ашыру | ТР МИ, ТР ХХЭбТЭhСЯМ, «СЮККО ярдәм күрсәтү буенча ресурс үзәге» АККО | 2022 – 2025 еллар | хезмәт күрсәтелгән мигрантлар саны, кеше | | | | | | | | | | 3 050 | 350 | 3 050 | 3 050 | | | | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты (министрлыклар һәм ведомстволарның төп эшчәнлеге) | Татарстан Республикасы бюджеты (министрлыклар һәм ведомстволарның төп эшчәнлеге) | Татарстан Республикасы бюджеты (министрлыклар һәм ведомстволарның төп эшчәнлеге) | Татарстан Республикасы бюджеты (министрлыклар һәм ведомстволарның төп эшчәнлеге) |

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «6.5. Татарстан Республикасындагы муниципаль районнарның авыл җирлекләре башлыклары өчен дәүләт милли сәясәтенең һәм дәүләт-конфессия мөнәсәбәтләренең актуаль мәсьәләләре буенча уку семинарларын оештыру | ТР МһФМ, ТР МҮИ (килешү буенча), ТР Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте департаменты (килешү буенча), ТР Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) | 2015 – 2019 еллар, 2021 – 2025 еллар | Татарстан Республикасындагы муниципаль районнарның укуда булган авыл җирлекләре башлыклары саны, кеше | - | - | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | - | 300 | 300 | 270 | 300 | 300 | - | 0,25 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,25 (Татарстан Республикасы бюджеты), 0,25 (федераль бюджет) | 0,27 (Татарстан Республикасы бюджеты), 0,1586 (федераль бюджет) | 0,28 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,29 (Татарстан Республикасы бюджеты) | - | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты) | 0,3 (Татарстан Республикасы бюджеты)». |

2. Бу карар 2023 елның 31 декабренә кадәр (31 декабрьне кертеп) гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин